**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**ЖУКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО**
**ПОСЕЛЕНИЯ**
**ТЕТЮШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО**
**РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТӘТЕШ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ЖУКОВО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422382 д. Жуково, ул. Векрхняя, 8

422382 Жуково авылы, Югары ур, 8

тел. (84373) 5-32-22, факс 5-32-22, e-mail guk.tet@tatar.ru
ОГРН 1061672018286 , ИНН/КПП 1638005033/163801001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**11 .03. 2025** **№ 11**

**Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Жуково авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген төзү һәм салым чыгымнарын бәяләүне уздыру тәртибен раслау турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 1743 статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең салым чыгымнарын бәяләүгә гомуми таләпләр турында " 2019 елның 22 июнендәге 796 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Жуково авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ::

1. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Жуково авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген төзү һәм салым чыгымнарын бәяләүне уздыруның кушымтада бирелә торган тәртибен расларга.
2. Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте идарәсенә 1 апрельгә кадәр Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Жуково авыл җирлеге башкарма комитетына хисап елындагы һәм хисап елына кадәрге елдагы һәр салым чыгымы буенча белешмәләр җибәрүне тәкъдим итәргә:

- ташламалардан файдаланган түләүчеләр саны турында;
- Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Жуково авыл җирлеге бюджетының төшеп кала торган керемнәре суммалары турында;
- Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Жуково авыл җирлеге бюджетына салым чыгымнарын стимуллаштыручы һәр салым чыгымы буенча түләүчеләр тарафыннан түләү өчен декларацияләнгән салым күләмнәре турында.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://tetushi.tatarstan.ru/.
4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Җитәкче** Н.А.Борисова